## Инспектор аңлата:

### Тикшерүләр программасы нинди максат белән эшләнә?

25.02.2015

**Җавап:** Тикшерүләр программасы инспектор тикшерүгә чыгарга хокуклы булган нигезләрнең берсе булып санала (Рәсми сайтның “Инспектор аңлата” бүлегендә 2015 елның 13 февралендәге «***Инспектор нинди нигезләрдә тикшерү үткәрә ала?»*** дигән сорауга җавапны карагыз).

***Тикшерүләр программасы*** капиталь төзелеш объектының конструктив һәм аны төзү, үзгәртеп кору эшләрен башкару кебек башка үзенчәлекләрен, алга таба аннан файдалану шартларын, шулай ук техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка норматив-хокукый актларның һәм проект документларының таләпләре нигезендә исәпкә алынырга тиешле башка факторларны исәпкә алып, төзелеш объектында күзәтчелек эшчәнлеген планлаштыру өчен ***Инспекциянең вазифаи*** заты тарафыннан эшләнә.

***Тикшерүләр программасы*** Инспекциядә (территориаль органнарда) эшләр башлану турында хәбәр алынганнан соң **<u>7 эш көне</u>** дәвамында эшләнергә тиеш.

**Тикшерүләр программасында** түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

а) РФ ШрК 48 статьясының 12 өлешендәге 6 пунктында каралган капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (алга таба – капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты) нигезендә билгеләнә торган, тикшерелергә тиешле эшләр исемлеге;

б) һәр тикшерү предметы;

в) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты белешмәләре нигезендә билгеләнә торган һәр тикшерүне үткәрүнең якынча вакыты;

г) һәр тикшерүне үткәрүгә дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы вазифаи затының чама белән сарыф ителәчәк вакыты;

д) дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы вазифаи заты тарафыннан тикшерү үткәрер өчен кирәкле булган башка мәгълүматлар.

Программа 2 нөсхәдә төзелә, аның берсе дәүләт төзелеш күзәтчелеге органында кала, икенчесе – төзүчегә яки техник заказчыга җибәрелә (тапшырыла).

*ТР ДТКИ матбугат хезмәте*